**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БИЛЯР-ОЗЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БИЛЯР-ОЗЕРО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Биляр-Озеро **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 1

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр - Озеро авыл җирлеге Биляр - Озеро торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр - Озеро авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Биляр-Озеро авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 16 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 16 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә,
3. 2019 елның 16 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Биляр-Озеро авылы Зеленая урамы, 15 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. 2019 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 30 минутка Биляр-Озеро авылы Зеленая урамы, 15 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

7. Сез Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Зирекле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;
- су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр башкару.

« ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы И.М.Шәрәфетдинов